РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 7 ноябре № 38

Түбән Кама шәһәр Советының
«Түбән Кама шәһәренең бюджет-финанс сәясәтен билгели торган
Нигезләмәне раслау турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәренең бюджет-финанс сәясәтен билгели торган Нигезләмәне раслау турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

8 статьяның 1 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бюджет һәм финанслар департаменты РФ Бюджет кодексы белән билгеләнгән финанс органы функцияләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзегәндә;»;

22 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль эчке бурыч алулар җирле бюджетны финанслау максатларында, шулай ук муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү, финанс елы дәвамында җирле бюджет счетларында калган акчаларны тулыландыру максатларында гамәлгә ашырыла.»;

22 статьяның 1 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле финанс елында акчаларны җәлеп итүнең гомуми суммасы, РФ Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле бюджет кытлыгын финанслауга җибәрелә торган акчаларның гомуми суммасыннан һәм җирле бюджет турында тиешле финанс елына расланган муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артмаска тиеш.»;

28 статьяның 2 пунктындагы 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яисә) муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр

елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына булган торышы буенча, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиге күрсәтелеп;»;

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисади үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин